КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 11 март г.Казань № 233

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 24 май, 349 нчы; 2015 ел, 30 март, 198 нче; 2016 ел, 24 март, 165 нче; 2017 ел, 22 апрель, 238 нче; 2018 ел, 9 апрель, 224 нче; 2018 ел, 10 сентябрь, 766 нчы; 2019 ел, 22 март, 214 нче; 2019 ел, 29 май, 455 нче; 2020 ел, 13 февраль, 106 нчы; 2020 ел, 12 июнь, 484 нче; 2021 ел, 23 март, 254 нче; 2021 ел, 3 август, 677 нче; 2022 ел, 28 февраль, 176 нчы; 2022 ел, 7 июнь, 529 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 19 301,34 млн.сум тәшкил итә, шулардан:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 19 136,51 млн.сум, шул исәптән:<br>2014 ел – 1 016,48 млн.сум; |

| | |
|---|---|
| | 2015 ел – 3 376,21 млн.сум;<br>2016 ел – 1 886,84 млн.сум;<br>2017 ел – 1 415,82 млн.сум;<br>2018 ел – 3 734,22 млн.сум;<br>2019 ел – 2 331,99 млн.сум;<br>2020 ел – 501,72 млн.сум;<br>2021 ел – 848,76 млн.сум;<br>2022 ел – 2 973,48 млн.сум;<br>2023 ел – 311,89 млн.сум;<br>2024 ел – 313,8 млн.сум;<br>2025 ел – 425,3 млн.сум;<br>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 164,83 млн.сум, шул исәптән:<br>2022 ел – 5,31 млн.сум;<br>2023 ел – 7,46 млн.сум;<br>2024 ел – 2,19 млн.сум;<br>2025 ел – 149,87 млн.сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм тиешле финанс елына бюджет проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

Программаның I бүлегендә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Программа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 17 ноябрендәге б-1662 номерлы боерыгы белән расланган 2020 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең озак сроклы социаль-икътисадый үсеше концепциясе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 6 октябрендәге б-2816 номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәр Россия Федерациясенең социаль-икътисадый үсеше инициативалары исемлеге, 2011 елның 22 апрелендәге 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2011 – 2015 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше программасы, 2015 елның 17 июнендәге 40-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын исемлеген раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нче карары нигезендә эшләнде.»;

уналтынчы абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 елның 26 июлендәге 35-ТРЗ номерлы (2011 елның 10 октябрендәге 35-ТРЗ номерлы редакциядә)» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте турында» 2022 елның 23 декабрендәге 96-ТРЗ номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 бүлекчәнең «2021 елда авария хәлендәге файдаланылырга яраклы булмаган объектларга кертелгән һәм исемлектән сызылырга тиешле Татарстан Республикасы милкендәге һәм муниципаль милектәге файдаланылмаган объектлар белән үткәрелгән чаралар турында мәгълүмат» таблицасыннан соң түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Күчемсез мөлкәтнең яңа объектларын төзүне планлаштырганда моңа кадәр гамәлдәге объектларны капиталь ремонтлау, реконструкцияләү яисә төзеп бетерү мөмкинлеген исәпкә алырга кирәк.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 19 301,34 млн.сум тәшкил итә, шулардан:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 19 136,51 млн.сум, шул исәптән:

2014 ел – 1 016,48 млн.сум;
2015 ел – 3 376,21 млн.сум;
2016 ел – 1 886,84 млн.сум;
2017 ел – 1 415,82 млн.сум;
2018 ел – 3 734,22 млн.сум;
2019 ел – 2 331,99 млн.сум;
2020 ел – 501,72 млн.сум;
2021 ел – 848,76 млн.сум;
2022 ел – 2 973,48 млн.сум;
2023 ел – 311,89 млн.сум;
2024 ел – 313,8 млн.сум;
2025 ел – 425,3 млн.сум;

җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 164,83 млн.сум, шул исәптән:

2022 ел – 5,31 млн.сум;
2023 ел – 7,46 млн.сум;
2024 ел – 2,19 млн.сум;
2025 ел – 149,87 млн.сум.

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм тиешле финанс елына бюджет проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.»;

Программаның V бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. Программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

Дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген бәяләү дәүләт идарәсенең матди нигезе буларак Россия Федерациясе субъекты дәрәҗәсендә дәүләт милкенең төрле функцияләренә бәйле булган нәтиҗәлелекнең төрле төрләрен билгеләүне күздә тота, ягъни:

социаль бурычларны хәл итү (мәгариф, сәламәтлек саклау, торак төзелеше һ.б.);

инженерлык инфраструктурасын тәэмин итү һәм үстерү (шул исәптән энергетика, транспорт өлкәсендә);

инвестицияләр җәлеп итү һәм стратегик инвестиция проектларын гамәлгә ашыру;

эшмәкәрлек үсеше өчен шартлар тудыру;

бюджетны дәүләт мөлкәтеннән файдаланудан һәм сатудан салым булмаган керемнәр белән тулыландыру.

Бюджетка кергәч, дәүләт милкен файдаланудан керемнәр бюджетның социаль сәясәткә, сәламәтлек саклауга һәм мәгарифкә чыгымнары өлешен каплауны тәэмин итә, алар территорияне үстерү буенча максатчан бюджет фондларын формалаштыру чыганагы булып тора һәм, димәк, дәүләт милке эшчәнлегенең икътисадый нәтиҗәсен генә түгел, социаль нәтиҗәсен дә билгели.

Моннан тыш, дәүләт милкен файдаланудан керемнәрнең абсолют зурлыгы бюджетны планлаштыру процессында билгеле бер әһәмияткә ия.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Программаның киләсе нәтиҗәлелеген бәяләү дә урын алып тора.

Икътисадый нәтиҗәлелек инвестиция климатын яхшырту, эшкуарлык эшчәнлеген үстерү өчен шартлар тудыру; транспорт һәм инженерлык инфраструктурасының тиешенчә эшләвен; бюджет даирәсенең матди базасын тәэмин итү белән билгеләнә.

Программа кысаларында икътисадый нәтиҗәлелеккә түбәндәге юнәлешләр буенча ирешеләчәк:

республика өчен түбәндәгеләр кебек стратегик инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүдә катнашу: Свияжск төбәкара мультимодаль логистик үзәген төзү; Югары Ослан районында «Иннополис Казан» территориаль аерымланган инновацион үзәген, шул исәптән Югары Ослан һәм Лаеш муниципаль районнарындагы мәйданчыкларда «Иннополис» техник-гамәлгә кертү махсус икътисадый зонасын; Лаеш муниципаль районында Малайзия консорциумы катнашында «СМАРТ-Сити Казан» төзү; «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасын киңәйтү;

җир кишәрлекләрен рәсмиләштергәндә нефть чыгару тармагын үстерү өчен шартлар тудыру;

дәүләт акцияләре портфеле белән идарә иткәндә корпоратив схемаларны гамәлгә ашыру һәм яңа структуралар булдыру юлы белән инвестицияләр җәлеп итү;

дәүләт һәм хосусый партнерлык формаларын үстерү;

дәүләт мөлкәте объектларын хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү нәтиҗәсендә эшмәкәрлек, кече һәм урта бизнес өлкәсен киңәйтү;

техник документацияне рәсмиләштерү һәм махсуслаштырылган эксплуатацияләү оешмаларына тапшыру юлы белән инженерлык инфраструктурасы (газ, җылылык челтәрләре һ.б.) объектларының тиешенчә эшләвен тәэмин итү.

Бюджет нәтиҗәлелеге дәүләт милке объектлары белән идарә итү, шул исәптән дәүләт мөлкәтен (шул исәптән акцияләр пакетларын, күчемсез мөлкәт объектларын) капиталлаштыру чараларының финанс нәтиҗәләрен, Татарстан Республикасы

бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре динамикасын чагылдыра.

Бюджет нәтиҗәлелеге өлешендә дәүләт мөлкәтен реализацияләүдән һәм файдаланудан, акцияләрне сатудан кергән акчаны файдаланудан Татарстан Республикасы бюджетының салым булмаган керемнәре түбәндәге күләмнәрдә фаразлана:

(млн.сум)

| Ел | Дәүләт мөлкәтен реализацияләүдән һәм файдаланудан, акцияләрне сатудан кергән акчаны файдаланудан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре |
|---|---|
| 2014 | 799,1 |
| 2015 | 917,9 |
| 2016 | 746,7 |
| 2017 | 1 925,4 |
| 2018 | 1 967,4 |
| 2019 | 450,9 |
| 2020 | 1 200,7 |
| 2021 | 826,9 |
| 2022 | 10 746,3 |
| 2023 | 527,9 |
| 2024 | 542,7 |
| 2025 | 547,8 |
| Барлыгы | 21 199,7 |

Әлеге саннарны бәяләгәндә түбәндәгеләрне игътибарга алырга кирәк. Фараз республиканың берничә төп предприятиеләре белән тармак идарәсендә катнашучы дәүләт катнашындагы зур холдинглар тарафыннан алынган керемнәрне үз эченә алмый. Шулай ук монда дәүләт катнашындагы зур компанияләр тарафыннан капиталлаштырыла һәм җитештерүне үстерүгә һәм социаль максатларга юнәлдерелә торган табыш кертелмәгән. Моннан тыш, Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтенең шактый өлеше керемле булып тормый, чөнки социаль һәм инфраструктура функцияләрен үтәүгә юнәлдерелгән.

Программаны гамәлгә ашырганда даими нигездә дәүләт катнашындагы предприятиеләрнең банкротлыгын профилактикалау, аларның рентабельлеген арттыру чаралары үткәреләчәк.

Шулай ук муниципаль милекне һәм җир кишәрлекләрен файдаланудан һәм сатудан кергән керемне, халык һәм оешмалар тарафыннан күчемсез мөлкәт объектлары тиешенчә рәсмиләштерелү исәбенә муниципалитетларның керем базасын киңәйтү процессын мониторинглау гамәлгә ашырылачак. 2021 елга муниципаль бюджетларның муниципаль мөлкәтне файдаланудан һәм сатудан алынган керемнә-ренең фараз күрсәткече – 4,5 млрд.сум.

Программаның социаль нәтиҗәлелеге түбәндәге юллар белән ирешеләчәк:

күпбалалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү (күпбалалы гаиләләр санының

даими үсешен исәпкә алып);

индивидуаль торак төзелеше, торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен гражданнарга, крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына дәүләт милкендәге җир кишәрлекләрен бирү срокларын оптимальләштерү;

социаль ипотека торак төзелеше;

уңайлы шәһәр мохите булдыру һәм территорияләрне төзекләндерү максатларында территориаль планлаштыруның сыйфатын яхшыртуны тәэмин итү;

җир кишәрлекләрен резервлау, алу, аларның категориясен үзгәртү юлы белән юл төзелешен тәэмин итү һәм юл буе инфраструктурасын үстерү;

дәүләт катнашындагы коммерция предприятиеләрендә гамәлдәге эш урыннарын саклап калу һәм яңаларын булдыру;

эшмәкәрләр һәм халык өчен дәүләт хезмәтләрен сыйфатлы күрсәтүне тәэмин итү, хезмәтләр күрсәтү срокларын оптимальләштерү һәм аларны электрон рәвешкә күчерү.

Җир-мөлкәт өлкәсендә коррупция күренешләрен профилактикалау буенча даими нигездә эш алып барылачак.

Моннан тыш, җир-мөлкәт өлкәсендә гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру процессын анализлау нигезендә халыкка тиешле хезмәтләр күрсәтү шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән нормативлар чыгару һәм башка инициативалар тәкъдим ителәчәк.

Идарә итүнең нәтиҗәлелеге идарә итү карарларын оператив һәм адекват кабул итү, идарә объекты составын һәм структурасын оптимальләштерү өчен шартлар тудыруны күздә тота.

Югарыда бәян ителгәннәргә бәйле рәвештә, дәүләт милке белән идарә итүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлтелгән чараларны эшләү һәм уздыру бурычлары актуаль булып кала.

Идарә итүнең нәтиҗәлелеген бәяләү дәүләт милке белән идарә итү системасының иң мөһим бурычларыннан берсе булып торуын билгеләп үтәргә кирәк: нәтиҗәлелекне үлчәү идарә итүнең кулланыла торган ысуллары нәтиҗәлелеген анализларга, аларның җитешсезлекләрен ачыкларга һәм идарәнең нәтиҗәлелеген арттыру юнәлешләрен билгеләргә мөмкинлек бирә.

Программа кысаларында идарә итү нәтиҗәлелеген тәэмин итү өлешендә түбәндәге юнәлешләр гамәлгә ашырылачак:

1) Дәүләт мөлкәте составын һәм структурасын оптимальләштерү.

Дәүләт милкендә бары аның төп функцияләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган мөлкәт тупланырга тиеш.

Программаның гамәлдә булу чорында оптимальләштерү юнәлешләре дәүләт унитар предприятиеләре санын, акцияләрнең дәүләт пакетларын, күчемсез мөлкәт объектларын кыскарту булачак.

Дәүләт унитар предприятиеләре түбәндәге очракларда гына сакланырга (булдырылырга) тиеш:

социаль әһәмиятле эшчәнлекне гамәлгә ашыру;

дәүләт сәясәте күзлегеннән караганда өстенлекле тармакларда эшләү;

законнар белән фәкать унитар предприятиеләр өчен генә каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру;

граждан әйләнешеннән алынган яисә граждан әйләнешендә чикләнгән, шулай ук Татарстан Республикасының һәм тулаем Россия Федерациясенең милли иминлеген тәэмин итә торган аерым продукция төрләрен җитештерү;

законнарда каралган башка очракларда.

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә Татарстан Республикасында агымдагы оештыру-хокукый формада 1 дәүләт унитар предприятиесен саклап калу планлаштырыла.

Акционерлык җәмгыятьләренә карата дәүләт функциясе милекче буларак корпоратив хокук механизмы аша гамәлгә ашырыла. Акцияләр пакетларының шактый өлеше миноритар үлчәмгә ия, бу дәүләткә идарә карарларын кабул итүгә реаль йогынты ясарга мөмкинлек бирми.

Дәүләт фонд портфеле структурасын оптимальләштерү дәүләтнең бюджет барлыкка китерүче предприятиеләрне, төп тармаклар предприятиеләрен, социаль әһәмиятле предприятиеләрне үз эченә алган стратегик әһәмиятле акционер җәмгыятьләрдә генә катнашуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасының фонд портфеле структурасы максатчан портфельгә шактый якын тора, әмма кайбер очракларда дәүләт акцияләр пакетлары хосусыйлаштырылырга тиешле рентабельле булмаган һәм аз санлы хуҗалык җәмгыятьләрендә катнаша. Фонд базарының тотрыксыз торышын һәм баш тартылырга тиешле акцияләр дәүләт акетларының ликвидлы булмавын исәпкә алып, аларны хосусыйлаштыру этаплап һәм уйлап башкарылачак.

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсез файдаланыла торган күчемсез мөлкәт объектларын хуҗалык әйләнешенә җәлеп итүне тәэмин итәчәк. Ел саен дәүләт мөлкәтен файдалануга карата үткәрелә торган тикшерүләр барышында нәтиҗәсез кулланыла торган яисә файдаланылмый торган мәйданнар ачыклана, аларның бер өлеше капиталь ремонттан соң дәүләт ихтыяҗлары өчен файдаланылачак, ә бер өлеше реализацияләнәчәк.

2) Дәүләт мөлкәтен тулысынча һәм дөрес итеп исәпкә алуны тәэмин итү.

Дәүләт мөлкәтен тулысынча һәм дөрес итеп исәпкә алуны тәэмин итү максатларында ел саен Дәүләт мөлкәте реестры күрсәткечләрен актуальләштерү чаралары башкарылачак. Шулай ук яңа исәпкә алу мәгълүмат системасын эшләү һәм гамәлгә кертү планлаштырыла (ул әлеге Программада каралмаган өстәмә финанс бирүне таләп итәчәк).

Программаны эзлекле, планлы һәм системалы гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы икътисады үсешен тәэмин итүдә мөһим шартларның берсе булып тора. Татарстан Республикасы мөлкәтенең оптималь структурасын формалаштыру республиканың функцияләрен һәм стратегик өстенлекләрен гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый идарә итү объектларын тотуга чыгымнарның авырлыгын киметергә, икътисадның коммерциячел секторының матди базасын киңәйтергә мөмкинлек бирәчәк. Кертергә планлаштырыла торган үзгәрешләр Татарстан Республикасы икътисадының конкурентлык сәләтен арттырырга һәм инновацион социаль юнәлешле үсешкә, инвестиция климатын сыйфатлы яхшыртуга, кирәгеннән артык административ һәм башка чикләүләрне киметүгә күчүне тизләтергә мөмкинлек бирәчәк.»;

Программаның кушымтасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин